ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

от 30.06.2023 г. Казань № 71-2/нпс-2023

Татарстан Республикасы өчен һәм аның составына керүче муниципаль берәмлекләр өчен халыкны техник карау пунктлары белән минималь дәрәҗәдә тәэмин итү нормативларын раслау турында

«Транспорт чараларын техник карау турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2011 елның 1 июлендәге 170-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Транспорт чараларына техник карау үткәрү кагыйдәләрен раслау, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 15 сентябрендәге 1434 номерлы, «Татарстан Республикасы өчен һәм аның составына керүче муниципаль берәмлекләр өчен халыкны техник карау пунктлары белән минималь рәвештә тәэмин итү нормативларын исәпләп чыгару методикасын раслау турында» 2011 елның 22 декабрендәге 1108 номерлы карарлары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 2023 елның 30 июнендәге 23-ПР номерлы беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Шушы карар кушымтасына туры китереп, Татарстан Республикасы өчен һәм аның составына керүче муниципаль берәмлекләр өчен халыкны техник карау пунктлары белән минималь дәрәҗәдә тәэмин итү нормативларын расларга.

2. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы өчен һәм аның составына керүче муниципаль берәмлекләр өчен халыкны техник карау пунктлары белән минималь дәрәҗәдә тәэмин итү нормативларын раслау турында» 25.08.2017 № 7-6/т карарының көчен югалтуын танырга.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Вакытлыча рәис
вазыйфаларын башкаручы Л.В.Хәбибуллина

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
30.06.2023 № 71-2/нпс-2023
карарына кушымта

Татарстан Республикасы өчен һәм аның составына керүче муниципаль берәмлекләр өчен халыкны техник карау пунктлары белән минималь дәрәҗәдә тәэмин итү нормативлары

| Тәртип саны | Россия Федерациясе субъекты, муниципаль берәмлекнең исеме | Халыкны транспорт чараларын техник карау пунктлары белән минималь дәрәҗәдә тәэмин итү нормативы <*> |
|---|---|---|
| 1 | Татарстан Республикасы | 47 |
| 1.1 | Казан шәһәре | 10 |
| 1.2 | Чаллы шәһәре | 8 |
| | Тукай муниципаль районы | |
| 1.3 | Әлмәт муниципаль районы | 3 |
| 1.4 | Әгерҗе муниципаль районы | 1 |
| | Менделеевск муниципаль районы | |
| 1.5 | Азнакай муниципаль районы | 1 |
| | Ютазы муниципаль районы | |
| | Баулы муниципаль районы | |
| 1.6 | Аксубай муниципаль районы | 1 |
| | Яңа Чишмә муниципаль районы | |
| | Чирмешән муниципаль районы | |
| | Нурлат муниципаль районы | |
| 1.7 | Актаныш муниципаль районы | 1 |
| | Минзәлә муниципаль районы | |
| 1.8 | Алексеевск муниципаль районы | 1 |
| | Әлки муниципаль районы | |
| | Спас муниципаль районы | |
| 1.9 | Апас муниципаль районы | 1 |
| | Кайбыч муниципаль районы | |
| | Кама Тамагы муниципаль районы | |
| | Тәтеш муниципаль районы | |
| 1.10 | Арча муниципаль районы | 1 |
| | Балтач муниципаль районы | |
| 1.11 | Бөгелмә муниципаль районы | 2 |
| 1.12 | Буа муниципаль районы | 1 |
| | Чүпрәле муниципаль районы | |
| 1.13 | Әтнә муниципаль районы | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| | Биектау муниципаль районы | |
| 1.14 | Алабуга муниципаль районы | 2 |
| 1.15 | Мамадыш муниципаль районы | 1 |
| 1.16 | Зәй муниципаль районы | 1 |
| 1.17 | Зеленодольск муниципаль районы | 1 |
| | Югары Ослан муниципаль районы | |
| 1.18 | Кукмара муниципаль районы | 1 |
| 1.19 | Лениногорск муниципаль районы | 1 |
| 1.20 | Мөслим муниципаль районы | 1 |
| | Сарман муниципаль районы | |
| 1.21 | Түбән Кама муниципаль районы | 3 |
| 1.22 | Питрәч муниципаль районы | 1 |
| | Балык Бистәсе муниципаль районы | |
| | Лаеш муниципаль районы | |
| 1.23 | Саба муниципаль районы | 1 |
| | Теләче муниципаль районы | |
| 1.24 | Чистай муниципаль районы | 2 |

---

<*> Күчмәләрен дә кертеп, Татарстан Республикасы территориясендә кирәкле диагностика линияләре саны.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф карарларын кабул
итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү
бүлеге